| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Красноборского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Красный Бор авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.05.2022 Красный Бор авылы № 15-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге Советының 2021 елның 17 декабрендәге 13-4 номерлы карары белән расланган 2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге бюджетына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге Советының 2021 елның 17 декабрендәге 13-4 номерлы карары белән расланган 2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге бюджетына кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны Красный Бор авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе А.Н.Лазарев